Татарстан Республикасы Нурлат шәһәре 13 нче номерлы «Талым” балалар бакчасы мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе

# “И моңлы, нурлы Тукай!”

(Г. Тукайның 129 еллыгын бәйрәм итү программасы)


Әзерләде:

МБМБУ 13 нче номерлы

“Талым” балалар бакчасының

1 категорияле тәрбиячесе

Шәйхетдинова Гөлия Наил кызы


2015 ел

*Зал бизәлешө: түрдә Г. Тукай портрете. Ул чәчөкләр һәм гөлләр бөлән бизәлгөн. Залның бөр ягында Тукай китапларыннан китап күргәзмәсе әзөрләнә. Магнитофон язмасында "И туган тел" көө яңгырый.*

***Алып баручы:*** *Тормышыңда бөйрәмнәр аз булган...*

*Тартыш белөн үткөн көннөрең,*

*Шуңа ахры искә алынмыйча*

*Үткән синөң туган көннөрөң.*

*Бөйрәмнәрең алда икән әле-*

*Кара, шагыйрь, бүгөн төкәлөп,*

*Халкың килде сиңа, мәхәббәтен*

*Ал чәчәкләр бөлән күтәреп.*

*Син күрмәгөн яңа буын килде*

*Котлап синең туган кәнөңнө,-*

*Киләчәккә барган улларыңнан*

*Ишөтөсең туган көнөңне-*

*Ишетәсең туган телеңне.*

*Буын арты буын алышыныр,*

*Гасыр арты узар гасырлар*

*Шигъриятнең һөйкөленә шулай*

*Язлар һаман гөлләр ташырлар.*

*Халык моңы- синең моңың булды,*

Халык күңеле- синең күңелең.

Ил гомере- халык гомере кебек

Озын булыр, шагыйрь, гомерең!

Кадерлө, балалар,! Без бүген татар халкының йөзек кашы булган сөекле шагыйребез Г. Тукайның туган көнен билгеләп үтү кичәсенә җыелдык.

Язның иң матур кеннәрендә милләттәшләребез, мәдәният хезмәткәрләре катнашында барлык мәктәпләрдә, балалар бакчаларында билгеләп үтелә торган зур бәйрәмнәрнең берсе- татар халкының сөекле шагыйре Габдулла Тукай туган кен.

Рус халкының Пушкин вә Лермонтовы булган кебек үк безнең Тукаебыз да үзенең кабатланмаслык иҗаты белән Беек һәм Даһи.

Кечкенәдән ул моңлы булып, шигырьләр, әкиятләр,халкыбызның җырларын тыңлап үсә.

Тукай абый турында без дә матур җыр ейрәндек. Әйдәгез, җырлап китик әле.

**Җыр “Тукай абый”.**

***Шүрәле*** ***керә.*** *Менә килеп тә җиттем. Исәнмесез, балалар! Мин дә бәйрәмгә килдем. Курыкмагыз, зыян салмам.Сезнең шигырьләр сөйләгәнегезне, җырлар җырлаганыгызны тыныч кына тыңлап утырырмын. Миңа урын бирерсезме?*

*Балалар җавабы.*

***Алып баручы.*** *Г. Тукай шигырьләре, әкиятләре кечкенәдән белем алырга, эш сеяргә, табигатьне сакларга, туган җирне яратырга өнди. Әйдәгез, балалар, шул шигырьләрне сейләп үтик. Шүрәле алдында сынатмыйк үзебезне.*

*(Балалар шигырь сейли)*

*Сәхнәдә күбәләк булып киенгән кыз бала “очып йөри.”*

**Алып баручы**. *Нинди матур күбәләк!*

*Сейләшикче бергәләп.*

***Җыр “Бала белән күбәләк.”***

***Алып баручы.*** *Балалар,әйдәгез, Шүрәле дустыбыз белән бергәләп уеннар да уйнап алабыз.*

***“Утыр, Мәликә”ьәм “Түбәтәй”уеннары***

***Шүрәле.*** *Бигрәк тәрбияле, тәртипле һәм күп белә торган балалар булып чыктыгыз әле сез. Мондый җырлар, шигырьләр һәм уеннарны беркайчан да ишеткәнем һәм уйнаганым да булмады.*

***Алып баручы.*** *Шүрәле дус, әле без сиңа тагын бер һөнәребезне күрсәтмәкче булабыз. Безнең кызларыбыз бик матур итеп бии дә беләләр әле. Рәхим итеп кара.*

***Кызлар башкаруында татар халык биюе.***

***“Су анасы”әкиятен сәхнәләштерү.***

***Алып баручы.*** *Күрдегезме, балалар, беркайчан да кеше әйберенә тияргә ярамый.*

***Шүрәле.****Бигрәк зирәк балалар булып чыктыгыз әле сез. Киләчәктә дә шундый акыллы, тырыш балалар булыгыз. Күп укыгыз, өйрәнегез. Тукай абыйны да, мине дә онытмагыз. Сау булыгыз.*

*(Үзенең бүләген балаларга тапшырып, Шүрәле китә.)*

***Алып баручы.*** *Әйе, сөекле Тукаебызны беркайчан да истән чыгармыйбыз. Аны яратабыз, зурлыйбыз. Шигырьләрен, әкиятләрен укып, яшәргә өйрәнәбез.*

*Туган телне яттан сөйләп,*

*Үсеп җиткәнбез шулай.*

*Барлык татар балалары*

*Ярата сине, Тукай.*

*Тылсымлы шигырьләреңне*

*Укыйбыз кабат-кабат.*

*Балачак хыялларына*

*Бирәләр алар канат.*

*Апрель җитсә, исемеңне*

*Җырына куша тургай.*

*Милләтемнең кояшы син*

*И моңлы, нурлы Тукай!*

*Бәйрәм* ***“И туган тел”*** *җырын җырлап тәгәлләнә.*

## Туган авыл.

Тау башына салынгандыр безнең авыл
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул.
Авылыбызның яме, суы тәмен беләм,
Шуңа күрә сөям җаным-тәнем белән.

Аябика
~~Г. Камиш~~

## Җир йокысы.

Кырга ак кардан
Юрган ябылган.
Җир язга чаклы
Йокыга талган.
Җир йоклый тыныч,
Күреп тәмле төш
Уяныр әле,
Тукта, үтсен кыш.

Ясмина

## Гали белән кәҗә

Безнең Гали бигрәк тату кәҗә белән
Менә кәҗә карап тора тәрәзәдән.
Гали аны чирәм белән кунак итә,
Кәҗә рәхмәт укый, сакалын селкетә.

Айсуль

## И туган тел

И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле.
Дөньяда күп нәрсә белдем,
Син туган тел аркылы.

Иң элек бу тел белән
Әнкәм бишектә көйләгән
Аннары төннәр буе
Әбкәм хикәят сөйләгән.

## Безнең гаилә

Әткәй, әнкәй, мин, апай, әби, бабай һәм бер песи-

Безнең өйдә без җидәү: безнең песи җиденчесе.

Бергә ашый, чәй эчә, безнең белән бергә йоклый ул.

Хезмәте дә бар: өйне тычкан явыздан саклый ул.

Адела

# Көз

Күрәмсез, дусларым, көз килде тышта
Озак тормас, килер ак тунлы кыш та Айсылу
Китә башлады инде бездән кошлар,
Алар бездән ерак җирләрдә кошлар.

Бөтен дөнья ап-ак булып кар яуганда,
Ишегалды, урам, түбә агарганда, Тагир
Ап-ак булып кайтып килә безнең бабай,
Безгә төрле- төрле уенчыклар алган да.

И туган тел һәрвакытта
Ярдәмең белән синең
Кечкенәдән аңлашылган
Шатлыгым, кайгым минем.

Бөтен дөнья ап-ак булып кар яуганда,
Ишегалды, урам, түбә агарганда,
Ап-ак булып кайтып килә безнең бабай, Камиль.
Безгә төрле-төрле уенчык алган да.
Шатланышып, без әйтәбез: „Рәхмәт, бабай,
Сиңа тагын күп еллар гомер бирсен Ходай!"
Бабай, мескен, кар-яңгырга карамыйча,
Безне шатландырмак өчен йөри шулай.